# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге составына керүче Түбән Яке торак пунктында 2022 елга үзара салым кертү турында

№3 «17» октябрь 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлегенең Түбән Яке торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Яке авыл җирлеге Түбән Яке торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, 90 яшьтән өлкәннәрдән кала, 2023 елда 500 (бишйөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Түбән Яке торак пункытында Ирек урамына юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Түбән Яке торак пунктында урамнарны яктырту буенча Энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Түбән Яке авылында зиратны койма белән әйләндереп алу (килешү буенча материал сатып алу)

- Түбән Яке авылында су башнясын койма белән әйләндереп алу (килешү буенча материал сатып алу)

- Түбән Яке авылында юлларны грейдлау һәм кардан чистарту

3. Әлеге карарны Яке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Яке авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Низаметдинов